ГЛАВА ВЕРХНЕНАЛИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ НАЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**21.03.2019** Югары Налим ав. **№ 1**

**«Аерым категориядәге затларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве белән бәйле рәвештә бүләк алуы турында хәбәр итү тәртибе, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 17 мартындагы 02 номерлы Югары Налим авыл җирлеге башлыгы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. «Аерым категориядәге затларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве белән бәйле рәвештә бүләк алуы турында хәбәр итү тәртибе, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 17 мартындагы 02 номерлы Югары Налим авыл җирлеге башлыгы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

1.1. 2 өлешнең 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләрен «комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләренә алмаштырырга.

2. Карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Налим**
**авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Н. Николаева**